*Нәбиуллина Г. Ә. (КФУ, Казан)*
*Галимова Г. Н. (КФУ, Казан)*

# ИДЕНТИЧНОСТЬ МОРАЛЬНО-ЭТИЧЕСКИХ ЦЕННОСТЕЙ В ТАТАРСКИХ И ТУРЕЦКИХ ПОСЛОВИЦАХ

**Аннотация:** В статье рассматриваются морально-этические ценности в контексте татарских и турецких паремий. Идентичность жизненных принципов, ментальности многих народов породило явление идентичности пословиц татар и турок. Материал, изложенный в данной статье может использоваться в процессе обучения татарскому языку и культуре.

**Ключевые слова:** пословица, морально-этические ценности, татарсикй язык, турецкий язык.

**The identity of moral and ethical values in Tatar and Turkish Proverbs**

**Abstract:** The article discusses moral and ethical values in the context of Turkish and Tatar paroemias. Identity life principles, the habits of many peoples gave rise to the phenomenon of identity Proverbs Tatars and Turks. The material is presented in this paper can be used in the process of learning the Tatar language and culture.

**Key words:** proverb, moral and ethical values, Tatarskii language, Turkish language.

Фразеологизмнар, паремияләр, афоризмнар билгеле бер телдә

сөйләшүче кеше аңында формалашкан мәдәни байлыклар турындагы мәгълүматларны туплый. Телнең афористик фонды, милли мәдәниятнең көзгесе кебек, үзләрендә гореф-гадәтләр, холыклар, фәлсәфи һәм эстетик байлыклар, теге яки бу телдә сөйләшүче халыкның дөньяны аңлавы, менталитет үзенчәлекләре турында белем бирәләр.

Паремияләр – халыкның төрле типтагы предикатив структурага ия булган хикмәтле фикерләре. Нәкъ менә мәкаль-әйтемнәр халык үзаңының, халык акыллылыгының, гореф-гадәтләренең һәм йолаларының гәүдәләнеше булып торалар.

Телнең паремиологик фонды лингвокультурологиянең тикшеренү предметы булып тора, чөнки күпчелек мәкаль-әйтемнәр ул – халык аңының тотрыклы, җитлеккән фикерләве (стереотипы). Гадәттә, мәкаль-әйтемнәр фольклористика фәнендә жанрлы текстлар буларак өйрәнелгәннәр. Лингвистикада аларны өйрәнү әле башланып кына килә. В. А. Маслова фикеренчә, прагматик күзлектән караганда, мәкальләрнең максаты шартлы: бер үк мәкаль шелтә дә, юаныч та, үгет-нәсихәт, киңәш буларак та аңлашыла ала.

Ә х л а к ы й - э т и к кыйммәтләрен тикшерүдә нигез итеп «Намус», «Әдәп-әхлак», «Рәхим-шәфкать», «Яхшылык-яманлык», «Сабырлык» турындагы татар һәм төрек мәкальләре алынды.

1) Намус кешедәге иң күркәм, иң кирәкле сыйфатларның берсе буларак күрсәтелә. Татар этник мәдәниятендә намус кыз-бала өчен аеруча мөһим сыйфат буларак тәкъдим ителә, намусын югалткан кыз, йөзен югалткан кебек күзаллана. Мәсәлән,

Казан карасы китәр, намус карасы китмәс; Кылыч ярасы китәр, намус карасы китмәс; Би билеген бирер, кыз намусын бирмәс; Чибәр кызның үлгәне – намусына тап төшкәне.

Төрек мәкальләрендә дә һәркемнең намусы үз кулында булуы һәм аны яшьтән үк сакларга кирәклеге, намусыңа кара төшерергә ярамау, намусның үлемнән өстен торуы ассызыклана. Мәсәлән,

erefsizce ya amaktansa, ereflice цlmek ye dir (Намуссыз яшәүгә караганда, намус белән үлү яхшырак), erefli olmak istersen, alzaklarla gцrъ me (Намуслы булырга теләсәң, намуссызлар белән аралашма).

2) Рәхим-шәфкать барлык күркәм гадәтләрнең башы, әдәплелекнең нигезе буларак бирелә. Татар паремияләрендә бу сыйфат балачактан ук тәрбияләнергә тиеш һәм

күпмедер дәрәҗәдә кешегә тумыштан ук салынган сыйфат буларак бирелә. Ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә карата аеруча рәхимле булырга, усал кешеләргә исә шәфкатьлелек күрсәтергә кирәкмәве искәртелә; табигатькә, төрле җан ияләренә карата мәрхәмәтле булу мөһим. Кайвакыт кешеләр хайваннардан, табигатьтән дә явызрак, рәхимсезрәк дигән фикер үткәрелә.

Рәхимле бүре рәхимсез кешенең баласын асраган; Рәхимсез кешедән рәхимле эт яхшы.

Бу үзенчәлекләр төрек мәкальләрендә дә күзәтелә:

Lokma karın doyurmaz, efkat arttırır (Бер кисәк белән тамак туймас, ә шәфкате артыр); Kцpek ekmek veren kapıyı tanır (Эт тә ипи ашаткан ишекне таный); Merhametten maraz do ar (Кемгә дә булса мәрхәмәт итсәң, җавабы начарлык булуы мөмкин)

3) Әхлак кешенең эш-хәрәкәтләрендә, көндәлек тормышында билгеле бер калыпка салынган сыйфат буларак тәкъдим ителә. Тикшеренүләрдән чыгып, күп очракта кешенең ниндилеген аның тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы, гадәтләре, сүзләре аша да сиземләп була, матур сыйфатларны кеше үзендә үзе тәрбияләп үстерә ала, әдәплелек хатын-кызлар өчен дә, ир-атлар өчен дә мөһим сыйфат булып тора. Әдәпле кешене солтан белән, әдәпсезне йөзен пычраткан кеше, олтан белән чагыштыру күзәтелә.

Әдәп башы – матур гадәт; Әдәп, әдәпнең төбе яхшы гадәт; Агач беленә җимешеннән, кеше – кыланмышыннан; Начарлыктан тыйган – әдәп, һәлак иткән – гадәт; Әдәпкә күнсәң, адәм булырсың, яманга күнсәң, әрәм булырсың; Яхшы гадәт адәм итәр, яман гадәт әрәм итәр; Үгет бездән, әдәп белү үзеңнән; Әдәп базарда сатылмый; Әдәп белән иплелекне базарда сатып алмассың; Әдәпле бул, халык сөяр; Әдәпне әдәпсездән өйрәнәләр.

Edep aklın dı tan gцrьnь ьdьr (Әдәп акылның тыштан күренүе); Ki inin edebi, altınından daha hayırlıdır (Кешенең әдәпле булуы бай булуыннан әйбәтрәк); Edeplerin anası, az konu maktır (Әдәпле булуның анасы – аз сөйләшү); Evladına edep ц retmeyen, dь manlarını sevindirir (Баласына әдәп өйрәтмәгән дошманын сөендерер).

4) Тыйнаклык Ислам диненең үзенчәлеге буларак тәкъдим ителә. Паремияләрдә тыйнаклыкның диннән килүе, кешене хөрмәткә, абруйдәрәҗәгә китерүе билгеләнеп үтелә, аның кыз-балалар өчен аеручы мөһим сыйфат булуына басым ясала. Тыйнаклыкның

бер билгесе буларак гадилеккә омтылу күрсәтелә.

Төрек телендә тыйнаклык күбрәк оят турындагы мәкальләр белән янәшә куела: Utangazlık yoksullarda, pervasızlık zenginlerde bulunur (Оялу ярлыда, ваемсызлык байларда була); Utangaz olmayan insanda erefte bulunmaz (Оят юкта намус та юк); Utanmak insanlara Allah tarafından bah edilmi bir lьtuftur (Оялу кешеләргә Алла тарафыннан бирелгән бүләк).

5) Татар паремияләрендә яхшылык-яманлык фәлсәфәсе иң үзәк темаларның берсе булып тора. Татар кешесе күзаллавынча, яхшылык эшләгәнеңне үзең әйтеп белдерү һәм яхшылыгыңа җавап итеп нәрсәдер өмет итү ярамый; кылган яхшылыклар югалмый, яхшылык та, яманлык та кешенең үзенә әйләнеп кайта. Яман эшләрдән тыелу кирәк, чөнки яхшы эшләрнең дә, яман эшләрнең дә гадәткә әйләнүе мөмкин; яхшы сүз, изге гамәл яхшылыкның бер билгесе булып торалар; яхшылык үлемнән өстен куела.

Яхшылык – төрек мәдәнияте өчен дә мөһим категория. Яхшылыкның дин белән бәйләп бирү күзәтелә, чөнки Ислам дине – кешеләрне тынычлыкка, мәрхәмәтлелеккә, яхшылыкка, намуслыкка өндәүче дин. Яхшылыкка – яхшылык, яманлыкка – яманлык кире кайта дигән фикер уздырыла, шуңа күрә күбрәк игелекле эшләр кылырга кирәк. Гадәткә әйләнмәсен өчен, яманлыкка иярергә ярамый, яман кешеләргә яхшылык эшләмә дигән фикерләр дә алга чыгарыла. Яман кешеләр бүреләр белән тиңләнә, кечкенә генә явызлыкларның зурга үсү мөмкинлеге ассызыклана, артык яхшы булу тәнкыйтьләнә.

Алтынга тут кунмас, яхшылык онытылмас; Алтын җирдә ятмас, яхшылык юлда калмас; Яшерен эшләгән яхшылык яктыда бүләк алыр; Яхшылык кыл да дәрьяга сал, балык белер, балык белмәсә, халык белер; Яхшылыкны эт тә онытмый; Яхшылык суга батмас, бер чыгар, тигез ятмас; Яхшылык яңа сауган сөт, каймагы өскә чыгар, бераз көт! Аш атканга аш ат, таш атканга таш ат; Яманлыкка каршы яманлык – үзе яхшылык; Яхшылыкка яхшылык, яманлыкка яманлык.

yili e iyilik her ki inin kвrı, kцtьь e iyilik er ki inin kвrı (Яхшылыкка яхшылык белән җавап бирүне һәркем булдырыр (Яманлыкка яхшылык белән җавап бирүне егет кеше (чын кеше) булдырыр – таш белән атканга аш белән ат); yili e iyilik olsaydı, koca цkьze bıзak olmazdı (Яхшылыкка һәрвакыт яхшылык җавап булса, күпме эш эшләгән үгезне иткә җибәрмәсләр иде); yili e

«nereye gidiyorsun» demi ler, «kцtьlь e» demi (Яхшылыктан «кая барасың?»дип сораганнар, «начарлыкка» дип җавап биргән, ягъни күп кенә яхшылыкларның җавабы начарлык); yilik et denize at, balık bilmezse Halik bilir (Яхшылык эшлә дә диңгезгә ат…); Bir kцtьnьn yedi mahalleye zararı vardır (dokunur) (Бер начарның җиде урамга зарары тия); Sa elinin verdi ini sol elin gцrmesin (уң кулың ни биргәнне сул кулың күрмәсен).

6) Татар лингвомәдәниятендә сабырлык тормышта хупланыла торган әхлакый сыйфат булып тора. Түземле, сабыр, азга канәгатьләнеп, булганына шөкер итеп торган кешеләр генә бәхетле була ала. Тикшеренүләрдән сабыр, канәгать булганнарның тормышы яхшырыр, эшләре уңар, сабырсыз һәм комсызларның исә ахмаклыгы гына артыр дигән нәтиҗәгә килә алабыз.

Шунысын да искәртеп узарга кирәк: татар һәм төрек паремияләрендә сабырлык кешегә табигать тарафыннан салынган сыйфат буларак күрсәтелә, ә сабырсызлык һәм канәгатьсезлек исә азгынлыктан килә. Сабырлык категориясе төрек лингвомәдәниятендә үзәк категорияләрнең берсе булып тора. Түземле, сабыр була белә торган кеше генә соңыннан теләгәненә, нинди дә булса казанышларга ирешә ала, ашыккан, түземсез кешегә хаталар ясау хас була дигән фикер үткәрелә. Сабырлык тормыш авырлыкларын җиңә ала дигән фикер йөртелә. Төрек паремияләрендә сабырлыкны ишәк, җавапсыз мәхәббәт, утта янган таш, җир, ук ату өчен куелган баганалар белән чагыштыру күзәтелә. Сабырлык һәм азга канәгать булу бер-берсеннән аерылгысыз категорияләр булып торалар, шул рәвешле азга канәгать булу сабырлык эчендә каралды. Сабыр булырга комачаулаган көч буларак нәфес күрсәтелә, төрек паремияләре аннан котылырга чакыра, мыскыллау, рәнҗетүләргә түземле булырга киңәш ителә.

Сабыр – гомерлек хәзинә; Сабыр итү – сары алтын; Сабыр төбе – сары алтын; Байлык бер айлык, канәгатьлек зур байлык; Канәгать үзе хәзинә; Сабырлык – адәм эше, ашыгу – шайтан фигыле; Адәм җаны – эт җаны; Кара кешенең тире чыкканчы сары кешенең каны чыгар; Беренә түзгән меңенә дә түзәр.

Sabır acıdır, meyvesi tatlıdır (Сабыр әче, җимеше татлы); Sabreden dervi muradına ermi (Сабыр иткән дәрвиш максатына ирешкән); Acele bir a aztır, meyvesi pi manlık (Ашыгу – агач, җимеше – үкенү); Allah sabırlı ulunu sever, Sabırla koruk helva olur, dut yapra ı

atlas (Сабыр булсаң, хәлвә куырылыр, тут агачы яфрагы атласка әйләнер).

Юмартлык категориясе татар лингвомәдәниятендә мөһим категорияләрнең берсе булып тора. Татар паремияләрендә юмарт кеше ачык йөзле, киң күңелле, байлыгын кызганмый торган, риясыз булып күзаллана. Әлеге сыйфат ир-егетләр өчен аеруча кирәкле һәм мөһим. Мәкаль-әйтемнәрдә юмартлык саранлыкка капма-каршы куела, шуның белән алар арасындагы аерма һәм мәгънә тирәнлеге тагын да ачыграк күзәтелә. Төрекләр ачык йөзле, кунакчыл халык, шуңа күрә юмартлык аларның күпчелегенә хас сыйфат, шуңа күрә төрек мәдәниятендә мөһим әхлакый категория булып тора. Һәр ике халыкта да ярлыларның юмарт булуы, байларның саран булуы күзәтелә; сараннар комсыз, юмартлар булганы белән канәгатьләнеп яшәүче кешеләр буларак тәкъдим ителә. Татар телендә дә, төрек телендә дә юмартлык белән саранлыкны бергә чагыштырып караган паремияләр шактый очрый.

Мәсәлән, татар халкында мондый мәкальләр бар: Юмарт дип була сорамыйча бирсә; Акыллы әйттерми белер, юмарт сорамый бирер; Биргән юмарт түгел, алган юмарт; Юмарт булсаң, үз кесәңнән бир; Кешенеке белән юмарт булма; Йөгерек ат туклыгын белдермәс, юмарт юклыгын белдермәс; Азгын тапса, аерым ашар, юмарт тапса, бергә ашар; Юмарт малын үзе ашар, саран малын эт ашар; Юмарт малын үзе ашар, саран малы саранның үзен ашар.

Cцmertin de cimrinin de sarıldı ı kefen aynıdır (Юмартның да саранның да кәфене бер); Parası ucuz olanın kendisi kıymetli olur (Акчасын кызганмый түккәннең кадере булыр); Az tamah зok ziyan getirir (саранлыкның кечкенәсе дә зур зыян салыр); Yemeyenin malını yerler (Саранланып мал җыйган кешенең малын башкалар тотып бетерерләр).

Шул рәвешле яхшылык, сабырлык, тыйнаклык категорияләре һәр ике телдә дә мөһим әхлакый-этик кыйммәтләр буларак күрсәтелә. Яхшылык категориясенә килгәндә, уртак яклар шундый: яхшылык та, яманлык та кешенең үзенә әйләнеп кайта, шуңа күрә яман эшләрдән тыелу кирәк; яхшы эшләрнең дә, яман эшләрнең дә гадәткә әйләнүе мөмкин, яманлыкка иярергә ярамау искәртелә. Һәр ике телдә дә сабырлык категориясе белән беррәттән, азга канәгать булу категориясе карала. Татар телендә дә, төрек телендә дә сабырлыкның уңышка, бәхеткә китерүе искәртелә. Әлеге ике категория ике тел дөнья кар-

тинасы өчен дә аеруча мөһим булган универсалийларны тәшкил итәләр. Әхлакый-этик кыйммәтләрдә халыкның милли сыйфатлары чагылыш таба. Тикшеренүләргә нигезләнеп, татарларга һәм төрекләргә хас универсалийлардан яхшылык белән юмартлык, сабырлык категорияләрен аерып күрсәтә алабыз. Шулай ук рәхим-шәфкать, изге гамәлләр кылу, яхшы холык, оялчанлык, тыйнаклык кебек кыйммәтләр уртак әхлакый-этик кыйммәтләрне тәшкил итәләр. Уртак кыйммәтләрнең күп булуы, беренче чиратта, дин уртаклыгы белән, татар-төрек мәдәнияте белән бәйле.

Әдәбият:

1. Җамалетдинов Р. Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре / Р. Р. Җамалетдинов. Казан: Мәгариф, 2006. 351 б.
2. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: 3 томда. Т. III / Н.С.Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967.1013 б.
3. Onarh I. Atasozleri ve Deyimler Sozlugu. Istanbul, 2001.